РЕСПУБЛИКА ТАТАРСТАН
СОВЕТ КАЙБИЦКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
КАЙБЫЧ МУНИЦИПАЛЬ
РАЙОН СОВЕТЫ

РЕШЕНИЕ КАРАР

16.07.2024 Олы Кайбыч ав. №275

Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына үзгәрешләр кертү турында

«Балигъ булмаганнар эшләре һәм Татарстан Республикасында аларның хокукларын яклау комиссияләре турында» 2011 елның 20 маендагы 26-ТРЗ номерлы Татарстан Республикасы Законының 7 статьясы нигезендә, Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы КАРАР ИТТЕ:

1. «Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе турында» 2022 елның 24 маендагы 122 номерлы Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районы Советы карары белән расланган Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районында балигъ булмаганнар эшләре һәм аларның хокукларын яклау комиссиясе составына түбәндәге үзгәрешләрне кертергә:

1.1. Комиссия составына түбәндәге әгъзаларны кертергә:

- Краснова Елена Мансур кызын - Кайбыч районындагы «Беренчеләр хәрәкәте» Россия балалар һәм яшьләр хәрәкәтенең жирле бүлекчәсе баш белгече;

- Ибраһимова Резедә Илгизәр кызын - Россия Гадәттән тыш хәлләр министрлыгы баш идарәсенең ТР буенча күзәтчелек эшчәнлеге һәм профилактика эше идарәсе Апас һәм Кайбыч районнары буенча күзәтчелек эшчәнлеге районара бүлеге инспекторы, эчке хезмәт лейтенанты (килешү буенча);

- Биккулова Илона Әнсар кызын - «Росдетцентр» ФДБУнең әйдәүче эксперты (килешү буенча) тәрбия буенча директорлар киңәшчеләре координаторы.

1.2. Комиссия составыннан Сөнгатуллина Сиринә Айрат кызын төшереп калдырырга.

2. Әлеге карарны Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http:/kaybici.tatarstan.ru веб-адресы буенча Татарстан Республикасы Кайбыч муниципаль районының рәсми сайтында һәм Интернет мәгълүмат-телекоммуникация челтәрендә http://pravo.tatarstan.ru веб-адресы буенча «Татарстан Республикасы хокукый мәгълүмат рәсми порталы»нда бастырып чыгарырга.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кайбыч муниципаль районы Советы Рәисе урынбасары Р.Р. Хәялиевка йөкләргә.

Совет Рәисе,
Кайбыч муниципаль районы Башлыгы А.И.Рәхмәтуллин